# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
Ромодан авыл җирлеге составына керүче
Масловка авылы торак пунктында

2020 елның 11 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ромодан авыл җирлеге составына керүче Масловка авылы торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елда Ромодан авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, гражданнарның үзара салымын 500 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге максатларга җибәрергә:
   - авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту;
   - урамнарны яктырту;
   - балалар уен мәйданчыгы өчен киртә сатып алу һәм урнаштыру;
   - тракторны карап тоту;

3. Әлеге карарны Ромодан авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Ромодан авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ромодан авыл җирлеге башлыгы И.А. Чекалина